Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № LVIII-7**

Балык Бистәсе штп. 2025 елның 7 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2024 елның 31 маендагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» XLIX-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2024 елның 31 маендагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» XLIX-4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 5.1.19 пунктының 1 нче пунктчасында «ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә» сүзләреннән соң «мәҗбүри таләпләр» сүзләрен өстәргә, « һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар салуны) китерүне булдырмау чараларын үткәрү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2) 6.4 пунктының 2 абзацында «контроль (күзәтчелек) органы заты» сүзләреннән соң «контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү мөмкин түгеллеге турында акт төзелгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

1.3) 8.4 пунктының 1 абзацында «төп күрсәткечләргә ирешүгә» сүзләреннән соң «шулай ук хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр әзерләү» сүзләрен өстәргә.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов